Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авылы җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 22 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 22 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 249 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 157 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 157 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту) буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту)

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге башлыгы ________________ С.М. Егоров